Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №LV-1**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 4 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мактаулы гражданины" исемен бирү турында" 09.11.2009 ел, №XXXXII-3 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мактаулы гражданины" исеме турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 30 статьясы нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мактаулы гражданины" исемен бирү турында" 09.11.2009 ел, №XXXXII-3 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мактаулы гражданины" исеме турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 2 бүлек. Мактаулы граждан исемен бирү нигезләренә һәм тәртибенә түбәндәге эчтәлекле 2.5 пункт өстәргә:

«2.5. Район Башлыгы Мактаулы гражданин исеме бирү өчен кандидатураны район Советы каравына шәхси инициативасы белән кертергә хокуклы.»;

1.2) 2.5 – 2.8 пунктларын тәңгәл рәвештә 2.6 – 2.9 пунктлары дип санарга;

1.3) 3 бүлектә. Мактау билгеләре һәм Мактаулы гражданнарны бүләкләү, 3.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы Р.Р. Ислямов